Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы

Чирмешән урта гомумбелем бирү мәктәбе

# Балаларның Интернет челтәрендә куркынычсызлыгы

Чирмешән урта мәктәбенең информатика укытучысы Сафарова Фидания Галимҗановнаның ата-аналар җыелышында ясаган чыгышы.

\

2012 ел

Белгәнебезчә, без XXI гасырда яшибез. Бу – мәгълүмати технологияләр гасыры. Мәгълуматларны җибәрү тизлегенең үсүе һәм компьютерларның җитештерүчәнлеге арту нәтиҗәсендә, кулланучылар үзара аудио- , видео- һәм текстлы мәгълуматлар белән аралашуны реаль вакытта башкару мөмкинлеге туды. Сайтларда фәнни статьялар, матур әдәбият текстлары, фотогалерея һәм тулы виртуаль музейлар, яңалыклар, биржадагы акцияләр курсы белән танышырга мөмкин. Өйдән чыкмыйча гына кешеләр белән танышырга, аралашырга мөмкин. Үзенең киң мөмкинлекләре нәтиҗәсендә «бөтендөнья пәрәвезе» зур популярлык яулады. Интернетның үсеше информацияне эшкәртүдә яңа эра башлану турында сөйли. Шулай да, Интернетның яхшы яклары белән беррәттән, аның тискәре яклары да бар.

Мәглүмати революцияләр тарихын искә төшерик:

*I мәглүмати революция* – **язу** барлыкка килү белән бәйле. Буыннан-буынга мәгълумат тапшыру мөмкинлеге барлыкка килә.

*II мәглүмати революция* – XVI гасыр уртасында **китап** басу белән бәйле. Бу җәмгыятьне, мәдәниятне, эшчәнлекне оештыруны тамырдан үзгәртә.

*III мәглүмати революция* – XIX гасыр ахыры – **электр** энергиясен уйлап табу. Аның нәтиҗәсендә телеграф, телефон, радио барлыкка килә, һәм бу оператив рәвештә мәгълуматны җиткерү, теләсә ни кадәр күләмдә туплау мөмкинлеген бирә. Барлык мәглүмати революцияләр дә мәгълуматның сыйфатын һәм алмашу тизлеген арттыра.

*IV мәглүмати революция* - XX гасыр ахыры – **Интернет.**

ИНТЕРНЕТ: яхшымы ул, әллә начармы?

Яхшы яклары:

- интерактив аралашу мөмкинлеге,
- бер-береңне күреп сөйләшү,
- аудио һәм видеоконференция,
- мәгълумат эзләү,
- Интернет-сату һәм банк операцияләре,
- Мавыгулар,
- Дистанцион белем алу,…

Начар яклары:

- Реаль вакыт виртуаль вакытка алмаша,
- Сәламәтлеккә зарар килә,
- Телефон челтәренең тулы булуы,
- Төрле шикле эчтәлектәге мәгълуматлар таралу,
- Төгәл булмаган мәгълумат алу мөмкинлеге,

- Азартлы уеннарга тартылу,
- Чатларда һәм башка өлкәләрдә «куркыныч» кешеләр белән очрашу,
- Кимсетүче, куркытучы аморалҗ контент,
- Компьютер вирусы эләктерү куркынычы.

Барысын бергә берләштереп, мондый нәтиҗәгә килергә мөмкин: Интернет белән эшләү – аралашуга, һәм традицион булмаган мәгълумат чыганакларына иңли алмаслык мөмкинлекләр ача. Үзенең ачыклыгы, интерактивлыгы, барлык кешеләр өчен дә куллана алу мөмкинлеге (доступность), кешеләрнең индивидуаль таләпләрен канәгатьләндерү мөмкинлеге Интернетны яңа глобаль массачыл мәгълумат алу чарасы итә. Интернет белән кулланырга һичшиксез кирәк, ләкин аңлы һәм грамоталы куллану таләп ителә.

9 яшьтән зуррак балалар, кагыйдә буларак, Интернетта нәрсә булу турында ишетеп беләләр. Алар моны үзләре күрергә, укырга, ишетергә телиләр. Бу нормаль күренеш. Интернет челтәренә тоташкан бала андагы теләсә-нинди матриалны карарга мөмкин. Бу – көчләү, наркотиклар, парнография, яшьләрне үз-үзләренә кул салырга этәрүче веб-битләр, анорекция (азык кулланудан баш тарту), үтереш һ.б.ш. Күп очракта, бу материалга килеп «эләгү» баладан бәйле дә түгел, чөнки күп кенә сайтларда махсус рәвештә үзлегеннән ачыла торган тәрәзәләр куялар, монда төрле мәгълумат, бигрәк тә еш очраганы парнография.

Ә Сез балагызның Интернетта нәрсә эшләвен беләсезме соң? Ата-ананың күзаллавы белән чынбарлык арасында бик зур аерма булуы да мөмкин бит. Бала, хәтта күзаллап та булмаслык куркыту-янаулар белән очрашырга мөмкин. Ә бит бала иң ышанучан, уязвимый кулланучы. Бер сайттан икенче сайтка күчә-күчә яңа тәэсирләр эзләгәндә, җиңел табыш эзләүче киберҗинаятьчеләр белән очрашу куркынычы килеп баса. Соңгы мәгълуматларга караганда, һәр бишенче бала теге яки бу җинаять максатына мишень булып тора. Ә сез, хөрмәтле әти-әниләр, үзегезнең балагызны Интернеттагы кирәкмәгән, ярамаган, сез теләмәгән материалдан чикли аласыз. Моның өчен, операцион системага беркетелгән «Родительский контроль» инструментын кулланырга мөмкин. Шулай итеп, сез кайбер уеннар, программалардан башлап, кирәкмәгән сайтларга кадәр блокировка куя аласыз. Үзлектән эшли алмаганда, белгечләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Интернет үсеше Фонды директоры, Мәскәү дәүләт университетының (МГУ) шәхес психологиясе кафедрасы профессоры Галина Солдатова әйтүенчә:

- Якынча 65% ата-аналар балаларын Интернет куллануда вакыт буенча да, тема буенча да чикләмиләр;
- Бары 5% балалар гына үзләренең әти-әниләренә нинди сайтларны кереп караулары турында әйтәләр, якынча 25%ы сирәк кенә әйтә, ә һәр бишенче бала беркайчан да әйтми;
- Сорау үткәрелгән балалар арасында яртысына якыны «риск группасы»на керә, чөнки алар Интернет аша танышкан кеше белән чынбарлыкта да бер булса да очрашкан;

- Балаларның яртысыннан артыгы үзләренең шәхси мәгълуматын (кәрәзле яки өй телефоны номерын, өй адресын, фотосурәтләрен Интернетка «элә».

**Балаларның Интернет челтәрендә куркынычсызлыгын тәэмин итү кагыйдәләре:**

- ✓ Интернет тоташкан компьютер барлык кешеләр дә керә торган уртак бүлмәдә булсын.
- ✓ Интернет белән куллану буенча «өй кагыйдәсен» булдырыгыз һәм балаларыгызның аны үтәвен таләп итегез.
- ✓ Балаларның компьютерда эшләү вакытын чикләгез.
- ✓ «Родительский контроль» яки пароль куеп, компьютер (бигрәк тә Интернет) куллануны чикләгез.
- ✓ Балаларга Интернеттагы кайбер кешеләрнең дөрес сөйләмәвен аңлатыгыз. Балалар, беркайчан да, Интернеттан танышкан кеше белән реаль тормышта үзләре генә очрашмаска тиеш. Явызлык кына теләүче кешеләр (наркоманнар, педофиллар), үзләрен баланың яшьтәше итеп күрсәтеп, яңа корбаннар эзләргә мөмкин.
- ✓ Балагызны компьютер куллануда чикләүче «учетная запись» булдырыгыз.
- ✓ Балагызның Интернеттагы дуслары турында сөйләшергә вакыт табыгыз.
- ✓ Балаларны шәхси мәгълуматларны ачмаска өйрәтегез. Интернетта телефон номеры, адрес, үзенең һәм гаиләнең фотосын куярга ярамавын аңлатыгыз. Бу фотосурәтне кемнең нинди максатта куллануын белеп булмый. Төрле монтаж фотошоптагы үзгәртүләр ярдәмендә рекламаларга элэгү куркынычы бар.
- ✓ Кечкенә балаларны олылардан башка программа урнаштырмаска өйрәтегез. Монда ялгыш вирус керүе һәм кирәкмәгән программа урнаштыру куркынычы тора. Вируслар керүдә иң куркынычы: электрон почта (таныш булмаган адрестан килгән хат – спамны ачмаска), Челтәрдән скачать ителгән файллар, лицензиясез компакт-дисклар, «флэшкалар» һ.б.
- ✓ Балаларны Интернет белән бәйле куркыту һәм тревогаларны Сезгә хәбәр итәргә өйрәтегез. Үзегез тыныч калырга тырышыгыз һәм, балаларыгыз үзләре хәбәр иткәнгә, аларга куркынычсыз булу турында искәртегез. Аларны мактагыз һәм киләчәктә дә шундый очракларда Сезгә мөрәҗәгать итү турында сүз куешыгыз.
- ✓ Балаларга Интернет челтәрен гайбәт яки янау тарату өчен кулланырга ярамавын аңлатыгыз.
- ✓ Балаларның үзләренең шәхси электрон почталарына Сезгә дә кереп карый алу мөмкинлеге бирүенә ирешергә кирәк. Моның белән Сез, хөрмәтле әти-әниләр, аларның нинди кешеләр белән аралашуын тикшерә аласыз.

Бергә булыйк, бердәм булыйк, балаларыбызны яклыйк һәм саклыйк!